КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 9 октябрь г.Казань № 1270

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстанда эшләнгән» порталы («Made in Tatarstan»)» Татарстан Республикасының сәнәгать потенциалы турында мәгълүмат ресурсының эшләү регламентын раслау турында» 2017 ел, 11 декабрь, 969 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстанда эшләнгән» порталы («Made in Tatarstan»)» Татарстан Республикасының сәнәгать потенциалы турында мәгълүмат ресурсының эшләү регламентын раслау турында» 2017 ел, 11 декабрь, 969 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы Порталның функциональ заказчысы тарафыннан Порталның мәгълүмати тулылануын һәм аннан файдалануын координацияләүче Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы булып торуын билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстанда эшләнгән» порталы («Made in Tatarstan»)» Татарстан Республикасының сәнәгать потенциалы турында мәгълүмат ресурсының эшләү регламентында:

1.2 пунктта:

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе» сүзләрен «Татарстан

Республикасының Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Порталның функциональ мөмкинлекләреннән файдалану өчен исәпкә алынган мәгълүматларны саклауны һәм фаш итмәүне тәэмин итә;

Порталда булган шәхси мәгълүматларны эшкәртүне оештыра һәм (яисә) гамәлгә ашыра, шәхси белешмәләрне эшкәртү максатларын, Порталдан файдаланып эшкәртелергә тиешле шәхси мәгълүматларның составын, законнар нигезендә гамәлләр (операцияләр) билгели.»;

7.5 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин